**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2012 ел, 24 декабрь № 1139

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының аларга Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән функцияләрне тормышка ашыру эшчәнлеген тәртипкә салу максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 февраль, 38 нче; 2007 ел, 13 июль, 297 нче; 2009 ел, 23 март, 161 нче; 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 22 февраль, 92 нче; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2011 ел, 6 июнь, 452 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 750 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 29 март, 250 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

01.05.01.01 кодлы функция исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын әзерләүне тәэмин итү».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 24 декабрь, 918 нче; 2009 ел, 23 гыйнвар, 31 нче; 2009 ел, 24 сентябрь, 659 нчы; 2009 ел, 18 декабрь, 863 нче; 2010 ел, 29 март, 199 нчы; 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы; 2010 ел, 12 октябрь, 798 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2011 ел, 6 июнь, 461 нче; 2011 ел, 13 август, 676 нчы; 2011 ел, 30 сентябрь, 816 нчы; 2012 ел, 3 февраль, 81 нче; 2012 ел, 10 август, 691 нче, 2012 ел, 18 октябрь, 871 нче карарлары редакциясендә) расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 нче пунктның бишенче абзацын төшереп калдырырга;

3.2 нче пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«территориаль планлаштыру (01.05.01.);».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 сентябрь, 464 нче; 2006 ел, 1 март, 87 нче; 2006 ел, 21 апрель, 198 нче; 2006 ел, 9 июнь, 293 нче; 2007 ел, 18 май, 196 нчы; 2008 ел, 29 май, 341 нче; 2008 ел, 15 июль, 509 нчы; 2009 ел, 17 август, 551 нче; 2010 ел, 8 июнь, 440 нчы; 2010 ел, 2 декабрь, 976 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 октябрь, 838 нче; 2012 ел, 22 август, 726 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
3.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа җиденче абзац өстәргә:
«Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын әзерләүне тәэмин итү (01.05.01.01<*>);»;
3.2 нче пунктның унҗиденче абзацын төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2012\1139.doc